РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.08-2017 № 1025-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 19 сентябрендәге 1195-п номерлы карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Керемнәрне исәпләүнең төрле механизмнарын куллануга бәйле гражданнар мөрәҗәгатьләре санын кыскарту максатларында, балалы гаиләләргә социаль ярдәмнең адреслы чараларын билгеләгәндә, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче һәм балага айлык пособие бирү тәртибен унификацияләү максатларында, “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 65 матдәсенең 2 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 19 сентябрендәге «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы балаларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» 1195-п номерлы карары (2015 елның 31 декабрендәге 1676-п номерлы, 2016 елның 12 маендагы 575-п номерлы, 2017 елның 14 мартындагы 267 номерлы карарлар редакциясендә) белән расланган компенсация түләүләре бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** түбәндәге эчтәлекле 1.7.һәм 1.8 пунктлар өстәргә:

«1.7. Әлеге карар нигезендә социаль ярдәм чараларын күрсәтүче органнар күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - ЕГИССО) куллану юлы белән һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматларга туры китереп бирү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәләр.

1.8. Әлеге Тәртиптә күрсәтелгән гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат ЕГИССО ны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕГИССО операторы тарафыннан билгеләнгән форматларга туры китереп файдаланырга мөмкин».

**2.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Җитәкче Р.М. Гасимов